**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 24 март № 178

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 724 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 724 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле «$б^1$» пунктчасын өстәргә:

«$б^1$) финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын раслаган көннән башлап мөлкәтләре милек хокукында Татарстан Республикасыныкы булган дәүләт унитар предприятиеләре тарафыннан, Контракт системасы турында Законның 15 статьясындагы $2^1$ һәм 6 өлешләр нигезендә гамәлгә ашырыла торган сатып алулардан тыш;»;

«в» пунктчасында «мөлкәтләре милек хокукында Татарстан Республикасыныкы булган дәүләт унитар предприятиеләре тарафыннан,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта:

«а» пунктчасының икенче абзацына «баш идарәчесе тарафыннан» сүзләреннән соң «алар билгеләгән вакытларда» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе законнары нигезендә аларның финанс-хуҗалык эшчәнлеген планлаштырганда сатып алулар планнарын формалаштыралар;»;

түбәндәге эчтәлекле «б$^1$» пунктчасын өстәргә:

«б$^1$) әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «б$^1$» пунктчасында күрсәтелгән дәүләт унитар предприятиеләре:

Россия Федерациясе законнары нигезендә аларның финанс-хуҗалык эшчәнлеген планлаштырганда сатып алулар планнарын формалаштыралар һәм аларны предприятиегә мөнәсәбәттә милекче вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы органнарга, алар билгеләгән вакытта, әмма агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча тапшыралар;

кирәк булганда сатып алулар планнарын тәгаенлиләр, алар тәгаенләгән һәм предприятенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын раслаганнан соң әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән вакытларда сатып алулар планнарын раслыйлар;»;

6 пунктта «б» һәм» сүзләрен ««б», «б$^1$» һәм» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктына түбәндәге эчтәлекле «ж» һәм «з» пунктчаларын өстәргә:

«ж) әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән заказчыга җиткерелгән Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә йөкләмәләрне кабул итү һәм (яки) үтәүгә хокукларның акчалата чагылыштагы күләме үзгәрү, мөлкәтләре милек хокукында Татарстан Республикасыныкы булган Татарстан Республикасының тиешле дәүләт бюджет учреждениеләре, дәүләт унитар предприятиеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары (программалары) күрсәткечләре үзгәрү, шулай ук субсидияләр бирү турында тиешле карарлар һәм (яки) килешүләр үзгәрү;

з) сатып алулар планын раслаган датага билгеле булмаган бүтән мөһим шартлар барлыкка килү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\178.docx